**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**НУРЛАТСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**
**ГЛАВА ЕЛАУРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯЛАУР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　Ялаур ав.　　　　КАРАР

«15» ноябрь 2024 ел　　　　№2

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлегенең Петровский поселогында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, муниципаль районның Ялаур авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка Петровский поселогы, Лесная урамы 19нчы йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Петровский поселогы Лесная урамындагы 2-32 нче йортларда яшәүчеләрдән үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын уздыруны билгеләргә
2. Гражданнар җыенын уздыру өчен Петровский бистәсендә яшәүчеләр исемлеген бүлүне сайлау тәртибен территориаль билге буенча башкарырга.
3. Гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Ялаур авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан Петровский бистәсендә яшәүче гражданнар өчен тәэмин ителә.
4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Ялаур авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 гр инвалидтан тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

«РИЗА»　　　　«КАРШЫ»

3. Әлеге карарны “Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

http://pravo.tatarstan.ru, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Петровский торак пунктының мәгълүмати стендларында, гражданнар җыены этаплары уздырылганчы 10 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә),

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Ялаур авыл җирлеге башлыгы О.В.Охотникова